# *Низамиева Мөнирә Касыйм кызы.*



*Мин, Низамиева Мөнирә Касыйм кызы, 1940 нчы елның 13 нче августында Олы Битаман авылында туганмын. Сугыш башланганда миңа бер яшь булган. Әтием Гыймадиев Касыйм сугышка киткән. Без әнием белән 5 бала: 3 малай һәм 2 кыз калганбыз. Әнием безне ач-ялангач итмәс өчен көнне төнгә ялгап эшләгән. 7 яшемнән басудан күкәрин җыйдым, кузгалак, какы, юа ише үләннәр белән туклandык. Әни кычыткан ашлары пешерә иде. Кечкенәдән эштә булдык, булдырган кадәр әнигә булыштык. Мәктәпкә укырга кереп, 5 нче класска кадәр укыдым. Аннан соң укырга мөмкинлек булмады, фермада сыер сава башладым. Сугыш беткәч, әтиебез кайтты. Без бик куандык. Ул ат җигүче булып эшләде, почта ташыды. 20 елдан соң авырып, 62 яшендә вафат булды. Мин үзем 40 ел фермада эшләдем. Коммунистлар партиясе члены булдым. Тырыш хезмәтем өчен "Ударник IX, XI, XII пятилетки", "Ударник коммунистического труда 1978 года", "Трудова слава СССР" күкрәк билгеләре, "Ветеран труда" исеме, "III дәрәҗә хезмәт даны ордены (Л № 311707) белән 1986 елда бүләкләндем. XXII район партия конференциясендә сайланган КПССның Биектау районы комитеты члены булдым 1978-1988 елларда. Тырыш, алыштыргысыз хезмәтем өчен 15 диплом, грамота, рәхмәт хаты белән бүләкләндем. Җыелыш, конференцияләрдә еш була идем.*

*Хәзерге яшьләр акыллы, тәртипле, әти-әниләренә мәрхәмәтле булсыннар иде. Сугышлар булмасын, ил-көнебез тыныч, күкләребез аяз булсын.*